**МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.07.2013 № 1330

**Казан ш.**

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашу бәйгеләрен үткәрү турында

2004 елның 27 июленнән булган № 79-ФЗ «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында»гы Федераль закон (үзгәрешләр белән), 2005 елның 1 февраленнән булган № 112 «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашу бәйгесе турында»гы Россия Федерациясе Президенты Указы (үзгәрешләр белән), 2003 елның 16 гыйнварыннан булган № 3-ЗРТ «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында»гы Татарстан Республикасы Законы (үзгәрешләр белән) таләпләренә туры китереп Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы аппаратының кадрлар составы белән эшен алга таба камилләштерү, шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы аппаратын югары һөнәри кадрлар составы белән тулыландыру һәм кадрлар резервын формалаштыру максатларында б о е р а м :

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашу бәйгесен үткәрү турындагы положениене (кушымта № 1).

1.2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга кандидатларга таләпләрне (кушымта № 2).

1.3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга кандидатлар бирә торган документлар һәм материаллар исемлеген (кушымта № 3).

1.4. Бәйгеләрдә катнашучыларны бәяләү критерийларын (кушымта № 4).

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашу бәйгесен үткәрү буенча бәйге комиссиясенең эшчәнлеген тәэмин итү бурычын Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар бүлеге башлыгы А.Ф. Салаватова өстенә куярга.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы эшләре белән Идарәнең мәгълүматый һәм инновацион технологияләр бүлеге башлыгы М.С. Нурмиевка үткәрелүче бәйгеләрнең мәгълүматый алып барылуын тәэмин итәргә.

4. 27.12.2006 булган № 1225 Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгын көчен югалткан дип санарга.

5. Шушы боерыкның башкарылуын тикшерүне үз өстемдә калдырам.

Министр А.З. Фәррахов

В.С. Шмелева,
(843)231-79-15

22.07.13 № 1330
ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгына
кушымта № 1

**Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашу бәйгесен үткәрү турында**

**ПОЛОЖЕНИЕ**

I. Төп кагыйдәләр

1.1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында (алга таба – бәйге комиссиясе) дәүләт граждан хезмәтенең (алга таба - дәүләт хезмәтенең) вакант вазыйфаларына урнашу бәйгесен үткәрү буенча бәйге комиссиясенең составы, вакытлары һәм эш тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашу бәйгесен үткәрү методикасы шушы Положение белән билгеләнә.

1.2. Положение Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына (алга таба - граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына) урнашу бәйгесен үткәрү тәртибен һәм шартларын урнаштыра. Граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашу бәйгесе (алга таба - бәйге) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә тигез рөхсәт алуга конституция хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба - гражданлык хезмәткәрләренең) бәйге нигезендә хезмәт үсешенә хокукларын тәэмин итә.

1.3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында (алга таба - Министрлык) бәйге 2004 елның 27 июленнән булган № 79-ФЗ «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында»гы Федераль законның 22 мәкаләсенең 1 өлеше һәм 2005 елның 1 февраленнән булган № 112 «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашу бәйгесе турында»гы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә үткәрелә.

Бәйге граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга претендентларның һөнәри дәрәҗәләрен, аларның бу урын өчен куелган квалификация таләпләренә туры килүләрен бәяләүдән гыйбарәт.

1.4. Министрлыкта бәйге Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау

министры (алга таба - Министр) карары буенча «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында»гы Федераль законга һәм «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турында»гы Татарстан Республикасының законына туры китереп граждан хезмәтенең бәйге нигезендә урнашып була торган вакант вазыйфалары булган очракта игълан ителә.

1.5. Бәйгене үткәрү турында карар вакансиясе булган структур бүлекчәнең җитәкчесе тарафыннан хәзерләнгән язма дәлилләүче гариза нигезендә Министр тарафыннан кабул ителә.

Бәйгене игълан итү турында тәкъдим белән беррәттән гаризада дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы (алга таба - граждан хезмәте вазыйфасы) исеме һәм хезмәт бурычларының үзенчәлекләрен исәпкә алу белән бергә бу вазыйфаны башкару претендентына куелган таләпләр булырга тиеш (шушы Положениегә кушымта № 1).

1.6. Министрлыкта бәйге үткәрелми:

а) Министрлыкта «җитәкчеләр» һәм «булышучылар (киңәшчеләр)» категорияләрен вәкаләтләрнең билгеле срогына урнашылучы граждан хезмәтенең вазыйфаларына эшкә билгеләгән очракта;

б) ашыгыч хезмәт контракты төзегән очракта;

в) 2004 елның 27 июленнән булган № 79-ФЗ «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында»гы Федераль законның 2 өлеше 28 мәкаләсе, 1 өлеше 31 мәкаләсе һәм 9 өлеше 60.1 мәкаләсе белән каралган очракларда граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгән очракта;

г) граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданны) граждан хезмәтенең вазыйфасына билгеләгән очракта;

д) граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә кагылучы граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына билгеләгән очракта.

1.7. Министрлыкның норматив актлары тарафыннан расланучы (14.01.2010 №11, 14.03.2012 №331 ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыклары) вазыйфалар исемлеге буенча, хезмәт бурычларын үтәү дәүләт сере булып торучы мәгълүматлар куллану белән бәйле булган граждан хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләгән очракта бәйге үткәрелмәскә мөмкин.

1.8. Бәйге түбәндәге максатларда үткәрелә:

Россия Федерациясе гражданнарының, аларның сәләтләре һәм һөнәри хәзерлекләренә туры китереп, дәүләт граждан хезмәтенә тигез рөхсәт алуга хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурслы нигездә хезмәт

үсешенә хокукларын тәэмин итү;

федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары куйган таләпләргә туры килүче һәм бәйгедә катнашырга рөхсәт ителүче кандидатларның гомуми санынннан граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашу өчен аеруча туры килүче кандидатларны сайлау;

Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.9. Бәйгеләр үткәрү вакытында хәл ителә торган бурычлар:

кандидатлар бәйге биремнәрен һәм процедураларын башкарган вакытта аларның барысы өчен дә тигез шартлар булдыру;

кандидатларны объектив һөнәри мөһим булган критерийлар нигезендә бәяләү;

бәйге процедуралары барышында алынган объектив һәм дәлилләнгән күрсәткечләрне чагыштыру ярдәмендә бәйгеләрдә катнашучылар арасында граждан хезмәтенең вакант вазыйфалары таләпләренә туры килүче шәхесләрне билгеләү.

2. Бәйге комиссиясенең формалашу һәм эшләү тәртибе

2.1. Бәйгене үткәрү өчен Министрлыкта Министр боерыгы белән даими нигездә эш итүче бәйге комиссиясе барлыкка килә.

2.2. Бәйге комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

Вәкаләтләрнең билгеле булмаган вакытына «җитәкчеләр» категорияләренең граждан хезмәте вакант вазыйфаларына урнашуга бәйге үткәрү өчен Министрлыкта бәйге комиссиясенең башында Министр тора.

Граждан хезмәтенең башка вакант вазыйфаларына урнашуга бәйгеләр үткәрү өчен Министр боерыгы белән граждан хезмәтенең төрле категорияләре һәм вазыйфалар төркемнәре өчен берничә бәйге комиссиясе барлыкка килә ала.

2.3. Комиссия рәисе бәйге комиссиясе эшчәнлеген җитәкли, утырышның үткәрү датасын билгели һәм аның көн чакырунамәсен раслый, комиссия утырышларында рәислек итә һәм тиешле документларга кул куя. Комиссия рәисе булмаганда аның хокукын һәм бурычларын бәйге комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Бәйге комиссиясе сәркатибе комиссиянең эшләвен тәэмин итә (теркәү, гаризалар кабул итү, делолар формалаштыру, комиссия беркетмәләрен алып бару һ.б.).

2.4. Бәйге комиссиясе составына Министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче, Министрлыкның идарәләре һәм бүлекләре: кадрлар

бүлеге, юридик, икътисад бүлекләре җитәкчеләре, Министрлыкның граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашу бәйгесе үткәрелүче структур бүлекчәсе җитәкчесе яки җитәкче урынбасары, Министрлыкның югары квалификацияле эшчеләре, Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча департамент вәкиле, шулай ук фән һәм белем бирү оешмалары, Министр соравы буенча экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә, граждан хезмәте белән бәйле сораулар буенча, бәйсез эксперт-белгечләр буларак Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча департамент тарафыннан чакырылучы башка оешма вәкилләре керәләр.

Министрлыкта вәкиле бәйге комиссиясе составына керүче иҗтимагый совет төзелгән.

Бу вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны бәйге комиссиясе әгъзаларының гомуми санының бер чирегеннән дә ким булмаска тиеш.

2.5. Граждан хезмәтенең дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар куллану белән бәйле булган хезмәт бурычларын үтәү буенча вакант вазыйфаларына урнашу бәйгесен үткәрү өчен бәйге комиссиясенең составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы закончылыгы кагыйдәләрен исәпкә алып формалаша.

2.6. Бәйге комиссиясе составы бәйге комиссиясе кабул итә торган карарларга тәэсир итәргә мөмкин булган мәнфәгать низаглары туу мөмкинлеген булдырмаслык итеп формалаша.

2.7. Бәйге комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына икедән дә ким булмаган кандидат булганда үткәрелә һәм анда аның әгъзаларының гомуми санының өчтән икесеннән дә ким булмаса хокуклы санала. Бәйге комиссиясе утырышын аның граждан хезмәте вазыйфаларында булган әгъзалары катнашуы белән генә үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Бәйге комиссиясе карарлар кабул итә:

бәйгене үткәрүнең план-графигын раслау турында;

бәйгенең икенче этабына үтәргә рөхсәт ителгән кандидатлар исемлекләрен раслау турында;

бәйге нәтиҗәләрен ясау турында;

бәйге процедураларын үткәрү нәтиҗәләре буенча төзелгән рейтингта беренче урынны алган кандидатларны бәйгенең җиңүчеләре итеп тану турында;

Татарстан Республикасы граждан хезмәте вакант вазыйфаларына урнашу өчен Министрлыкның кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатлар исемлекләрен

формалаштыру турында.

2.9. Бәйге үткәрү нәтиҗәләре буенча бәйге комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән аның утырышта булучы әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда хәл итүче булып бәйге комиссиясе рәисе тавышы тора. Бәйге комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы кабул ителгән карар белән килешмәгәндә комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә һәм бәйге комиссиясенең шушы әгъзасының имзасы белән берегә торган аерым фикерен белдерә ала.

2.10. Бәйгедә катнашучыларга карата бәйге комиссиясе түбәндәге карарлар кабул итә:

а) граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашу өчен куелган таләпләргә аеруча туры килә, граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына эшкә билгеләнү өчен тәкъдим ителә;

б) граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашу өчен куелган таләпләргә туры килә, тиешле кадрлар резервына кертү өчен тәкъдим ителә;

в) граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашу өчен куелган таләпләргә туры килми.

2.11. Бәйге комиссиясенең карары кандидат булмаганда кабул ителә һәм аны граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына эшкә билгеләү яки кадрлар резервына кертү, яки боларны кире кагу өчен нигез булып тора.

2.12. Бәйге комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителүче карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре) рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм утырышта катнашкан комиссия әгъзалары кул куя торган бәйге комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштереләләр (шушы Положениегә кушымта № 2).

2.13. Бәйге процедурасын эшләп чыгару һәм әзерләү буенча эшче документларның, бәйге комиссиясе утырышлары беркетмәләренең эчтәлеге, сораулар исемлеге һәм бәйге биремнәре темалары бәйге тәмамланганчы хезмәт өчен кулланыла торган мәгълүмат булып торалар.

2.14. Бәйгене оештыруны һәм үткәрүне, бәйге комиссиясе эшен тәэмин итүне турыдан-туры Министрлыкның кадрлар бүлеге башкара.

3. Бәйгеләрдә катнашучылар

3.1. Министрлыкның граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга кандидатларга булган таләпләргә туры килүче һәм билгеләнгән вакытта барлык кирәкле документларны биргән гражданнар (алга таба кандидатлар дип аталалар) бәйгедә катнашуга рөхсәт ителәләр.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга кандидатларга таләпләр (22.07.2013 булган № 1330 Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгына кушымта № 2) һәм Министрлыкта граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга кандидатлар тарафыннан бирелүче документлар һәм материаллар исемлеге (22.07.2013 булган № 1330 Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгына кушымта № 3), Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтен регламентлаучы норматив хокук актлары нигезендә урнаштырылганнар.

3.2. Бәйгедә катнашу өчен документлар аларны кабул итү турында игълан ителгәннән соң 21 көн эчендә кандидатлар тарафыннан бәйге комиссияләренә тапшырылалар.

3.3. Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданинга аларны кабул итүне кире кагуга нигез булып тора, аның турында гражданин өч көн эчендә язма рәвештә белдерелә.

Документларны нигезле сәбәп аркасында вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда аларның тапшырылу вакытлары күчерелергә мөмкин.

## 4. Бәйгеләр үткәрү методикасы

4.1. Бәйге үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяли торган ысулларга нигезләнгән, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокук актларына каршы килми торган бәйге биремнәре һәм процедуралар файдаланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийлары Министрлыкның граждан хезмәте вазыйфаларына куелган квалификация таләпләре нигезендә эшләп чыгарылган.

Бәйгедә катнашучыларны бәяләү критерийларының үрнәк исемлеге һәм кыска тасвирламасы 22.07.2013 булган № 1330 Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгына № 4 кушымтада китерелгән.

Бәйге үткәрелә торган вазыйфаларның төркеменә һәм категориясенә карап бәйгедә катнашучыларны бәяләү критерийлары үзгәрергә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлау аларның бәйге биремнәрен башкарулары һәм бәйге процедураларын үтүләре нәтиҗәләре нигезендә ясала.

Нәтиҗәләр баллар буенча тәртипкә салынган кандидатлар исемлеге (рейтинг) рәвешендә күрсәтелә.

4.4. Бәйге ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Министрлык бәйгене үткәрү һәм документлар кабул итү турындагы мәгълүматны аларны кабул итү турында игълан ителгәннән соң 21 көн эчендә Министрлык сайтында урнаштыра (шушы Положениегә кушымта № 4).

Министрлык сайтында граждан хезмәте вакант вазыйфасының исеме, бу вазыйфага урнашу өчен кандидатларга куелган таләпләр, бәйге комиссиясенә тапшырылырга тиеш булган документларны кабул итүнең урыны, вакыты һәм срогы, шулай ук бәйге турында тулы мәгълүматның чыганаклары турында мәгълүматлар (телефон, факс, электрон почта, Министрлык сайтының электрон адресы, документлар кабул итү өчен җаваплы булган шәхеснең фамилиясе, исеме, атасының исеме), шулай ук граждан хезмәте узуның шартлары турында мәгълүмат күрсәтелә.

Бәйгенең беренче этабы бәйгедә катнашу өчен документлар кабул итү турында Министрлык сайтында бастырып чыгару көненнән башлана һәм 21 көннән дә иртәрәк булмыйча тәмамлана.

4.4.2. Беренче этапта бәйге комиссиясе:

федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокук актларына каршы килми торган кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү ысулларын файдаланып конкрет бәйге процедураларын (шәхси әңгәмә, анкеталау, төркем дискуссияләре үткәрү, граждан хезмәтенең кандидатлар урнашырга дәгъвалый торган вакант вазыйфасы буенча хезмәт бурычларын башкару белән бәйләнгән сораулары буенча реферат язу яки тест эшләү) билгели, комиссия составы раслана;

граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга дәгъвалый торган гражданнарны бәйге үткәрү шартлары турында мәгълүмат белән тәэмин итә һәм сорауларга җавап бирә;

бәйге документларын кандидатлардан алынган сораулар буенча кәгазь формасында бер көнлек срокта бирә;

кандидатларның куелган таләпләргә туры килүен алдан бәяли.

4.4.3. Граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга, Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшергәннән соң, бәйге комиссиясе Министрга гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә) бәйгедә катнашуга рөхсәт бирү турында яки аларның бәйгедә

катнашуын дәлилле кире кагу турында карар кабул итү өчен үз тәкъдимен кертә.

Министрга кандидатларның тикшерелгән документлары һәм бәйге комиссиясенең тәкъдиме бәйгенең икенче этабын үткәрү турында карар кабул итү өчен бирелә.

4.4.4. Бәйгенең икенче этабын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында карар граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга претендентлар тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген тикшергәннән соң, шулай ук дәүләт серен һәм закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматлар алуга рөхсәт кирәк булганда рәсмиләштерүдән соң эшкә яллаучының вәкиле тарафыннан кабул ителә.

4.4.5. Эшкә яллаучының вәкиле бәйгенең икенче этабы башланырга 15 көннән дә соң түгел аның үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында бәйгедә катнашырга рөхсәт ителгән гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә) хәбәрләр җибәрә.

4.4.6. Икенче этапта бәйге комиссиясенең сәркатибе бәйге комиссиясе утырышын үткәрүгә кадәр алдан биш эш көненнән дә соңга калмыйча бәйге комиссиясенең бөтен әгъзаларына бәйгедә катнашучылар тарафыннан тапшырылган документларның күчермәләрен бирә.

4.4.7. Тикшерү барышында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закончылыгына туры китереп гражданинның граждан хезмәтенә урнашуына киртә булучы шартлар ачыкланган очракта, ул кадрлар бүлеге тарафыннан язма формада бәйгедә катнашуны кире кагуның сәбәпләре турында өч көнлек срокта хәбәр ителә (шушы Положениегә кушымта № 5).

4.4.8. Кандидатларны тест ярдәмендә сынау язма формада үткәрелә. Бәйге комиссиясе претендентларны тест ярдәмендә сынау өчен сораулар исемлеген төзи, шулай ук дөрес булмаган җаваплар санының (яки процентының) чиген раслый. Рөхсәт ителүче дөрес булмаган җавапларның саны 25 проценттан да күбрәк була алмый.

Сораулар исемлеге гомум танышу өчен ачык булырга тиеш. Тест сораулар исемлеге нигезендә төзелә һәм бәйгедә катнашучының түбәндәгеләрне белүен тикшерүне тәэмин итәргә тиеш:

Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясен; Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнарын;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турында закончылыгын;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы

положениене;

граждан хезмәте вазыйфасының хезмәт регламентын;

структур бүлекчәнең эшчәнлеге юнәлеше буенча норматив хокук актларны.

Тестта 50 артык сорау булырга тиеш түгел.

4.4.9. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә бәйге комиссиясе граждан хезмәте вазыйфасының һәм шул вазыйфа буенча хезмәт регламентындагы башка кагыйдәләрнең, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы закончылыгы һәм шушы Положение тарафыннан урнаштырылган башка кагыйдәләрнең тиешле квалификация таләпләреннән чыгып эш итә.

4.4.10. Бәйге комиссиясе әгъзалары претендентларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын кадрлар бүлегенең һәр бәйгегә әзерли торган бәяләү битләрендә билгелиләр.

4.4.11. Бәйге башланыр алдыннан бәйге комиссиясе утырышында рәис булучы бәйге комиссиясе әгъзаларына аны үткәрүнең, бәяләр куюның тәртибе турында, бәйге комиссиясе әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары турында инструкция үткәрә.

4.4.12. Бәйге комиссиясенең һәр әгъзасы бәйге комиссиясе сәркатибеннән бәйгедә катнашучыларның бөтенесенә бәяләү битләрен ала һәм тиешле баллар куя. Һәр бәяләү битендә балларның гомуми санын куйганнан соң бәйге комиссиясе әгъзасы бәяләү битләренә кул куя һәм аларны бәйге комиссиясе сәркатибенә тапшыра.

4.4.13. Бәяләү битләре нигезендә бәйге комиссиясе сәркатибе бәйгедә катнашучыларның һәрберсе алган барлык балларны куша.

Бәяләү битендә төзәтүләр рөхсәт ителми.

Кандидатларны бәяләүнең йомгаклаучы нәтиҗәләре анкетага кертелә (шушы Положениегә кушымта № 7).

4.5. Икенче этапның нәтиҗәсе һәм берьюлы бәйгенең йомгаклаучы нәтиҗәләре булып бәйге комиссиясе әзерләгән граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга кандидатлар рейтинглары торалар.

Бәйгегә нәтиҗәләр ясау һәм граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга кандидат турында карар кабул итү өчен нигезләр булып түбәндәгеләр торалар:

бөтен бәйге процедураларын үтү нәтиҗәләре буенча кандидатлар алган бәяләү критерияләре буенча баллар суммалары;

кандидатлар белән әңгәмә үткәрү нәтиҗәләре буенча кандидатлар дәгъвалый торган вазыйфасы булган структур бүлекчәнең җитәкчеләре фикере (Министрлык җитәкчелеге фикере).

Бәйге комиссиясе бәйге җиңүчесе турында карарларны, шулай ук Министрлыкның кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеген раслый.

4.6. Әгәр бәйге үткәрү нәтиҗәсендә урнашуга бәйге игълан ителгән граждан хезмәтенең вакант вазыйфалары буенча кирәк булган бөтен таләпләргә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, бәйге комиссиясе өстәмә бәйге сынаулары үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа бәйге үткәрү турында тәкъдим кертергә хаклы.

4.7. Министр яңа бәйге үткәрү турында яки вакант вазыйфага урнашу өчен куелучы таләпләргә иң туры килүче һәм балларның иң зур санын җыйган бәйгедә катнашучыны дәүләт граждан хезмәте турындагы закончылыкка туры китереп граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына максималь сынау вакыты белән эшкә билгеләү турында карар кабул итә.

4.8. Әгәр бәйгедә катнашучыларның икесе яки аннан да күбрәге иң зур баллар санын тигез күләмдә җыйсалар, хәл итүче булып бәйге комиссиясе рәисенең фикере тора.

4.9. Бәйге комиссиясе карарында граждан хезмәте вазыйфасына беренче тапкыр алынган гражданин өчен сынау срогының дәвамлылыгы буенча рекомендация бирелергә мөмкин.

4.10. Бәйге нәтиҗәләре буенча бәйге җиңүчесенең дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына эшкә билгеләнүе турында Министр боерыгы басыла, һәм аның белән хезмәт контракты төзелә.

Граждан хезмәткәрен (гражданинны) - бәйге җиңүчесен кадр резервына кертү граждан хезмәткәренең шәхси делосына тиешле язманы һәм граждан хезмәткәренең хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документларны кертеп Министр боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Шуның белән бергә вазыйфалар номенклатурасына туры китереп, бәйге җиңүчесен вазыйфага эшкә билгеләнүгә тәкъдим иткәндә, Министрга мәҗбүри тәртиптә бәйге комиссиясе карары һәм комиссия тарафыннан шундый карар кабул итү өчен нигез булган материаллар тапшырыла.

4.11. Граждан хезмәте вазыйфасына урнашуга претендент Россия Федерациясе закончылыгы белән туры китереп бәйге комиссиясе карарына шикаять бирергә хаклы.

4.12. Бәйгедә катнашкан кандидатларга кадрлар бүлеге тарафыннан бәйге нәтиҗәләре турында язма формада  аның тәмамлану көненнән башлап җиде көнлек срокта белдерелә (шушы Положениегә кушымта № 8) һәм тиешле мәгълүмат әзерләнә (шушы Положениегә кушымта № 9).

Бәйге нәтиҗәләре турында мәгълүмат Министрлык сайтында урнаштырыла.

4.13. Граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга бәйгедә катнашуга кертелмәгән претендентларның һәм бәйгедә катнашкан кандидатларның документлары аларга бәйге тәмамланганнан соң өч ел эчендә язма гариза буенча кайтарылырга мөмкин. Бу срок беткәнче документлар Министрлык архивында саклаcalar, аннан соң юк ителергә тиеш булалар.

4.14. Бәйгедә катнашу белән бәйле булган чыгымнар (бәйге үткәрү урынына килү һәм китү, торак бүлмә яллау, яшәү, элемтә чаралары белән куллану һәм башкалар) үз чаралары хисабына кандидатлар тарафыннан тотыла.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында дәүләт
граждан хезмәтенең вакант
вазыйфасына урнашуга
бәйге үткәрү турындагы
Положениегә кушымта № 1

Форма

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрына

______________________________
(структур бүлекчә исеме)

Дәүләт граждан хезмәтенең
вакант вазыйфасына урнашуга бәйге үткәрү турында
гариза

Сездән дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга бәйге игълан итүегезне сорыйм__________________________________________________
(вазыйфа, бүлек, Идарә исеме)

Бу вазыйфага урнашуга претендентка түбәндәге таләпләр куела:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Кушымта:
Граждан хезмәте вакант вазыйфасының хезмәт регламенты күчермәсе.

________________________
(вазыйфасы)
(имза)

20____елның «__»____________

Килешенгән
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министры урынбасары
_________________(Е.И. Шишмарева)
(имза)
20 __елның «___»__________

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында дәүләт
граждан хезмәтенең вакант
вазыйфасына урнашуга бәйге
үткәрү турындагы положениегә
кушымта № 2

Форма

Бәйге комиссиясе протоколы № _______

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының бәйге комиссиясе утырышында урнашыла торган вакант вазыйфага бәйгеле сайлап алу буенча тавыш бирү үткәрелде _____________________________________________
(урнашыла торган вакант вазыйфаның исеме)
_____________________________________________________________________________
(структур бүлекчә исеме)

Утырышта бәйге комиссиясенең _____ әгъзасыннан______ булды.
Карар:
1.________________________________________«риза» _____, «каршы» ______
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
2.________________________________________«риза» _____, «каршы» ______
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
3.________________________________________«риза» _____, «каршы» ______
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча
_____________________________________________________________________________
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
тавыш бирүдә катнашкан комиссия әгъзалары саныннан_______процентны тәшкил итеп, бәйге комиссиясе әгъзалары тавышларының иң күп санын алды.

Бәйге комиссиясе рәисе ________________________________
Бәйге комиссиясе рәисе урынбасары ________________________________
Бәйге комиссиясе сәркатибе ____________________________
Бәйге комиссиясе әгъзалары:____________________________

Бәйгене үткәрү датасы 20__елның «___»__________

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында дәүләт
граждан хезмәтенең вакант
вазыйфасына урнашуга бәйге
үткәрү турындагы положениегә
кушымта № 3

Форма

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы
граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга (кадрлар резервына кертүгә)
бәйгедә катнашу өчен документлар кабул итү турында
белдерү

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга бәйге (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар резервына кертүгә бәйге) үткәрә:

___

(урнашылучы вазыйфа исеме)

Квалификация таләпләре:

белгечлек буенча югары белем (нинди икәнен күрсәтергә), белгечлек буенча хезмәт стажы: ике елдан да ким булмаган граждан хезмәте стажы (бүтән төрле дәүләт хезмәте) яки өч елдан да ким булмаган белгечлек буенча хезмәт стажы*.

Бәйгедә катнашырга теләүче гражданнар түбәндәге документларны бирә:

шәхси гариза,

үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета,

паспорт күчермәсе,

тиешле һөнәри белемне, хезмәт стажын һәм квалификацияне раслаучы документлар,

гражданинда граждан хезмәтенә урнашуга яки аны үтүгә киртә булучы авыруларның булмавы турында медицина йомгаклавы (001 -ГС/у формасы),

почмакчыксыз каралы-аклы сурәттә ялтыравыксыз кәгазьдә эшләнгән ике фотография (4х6).

Бәйгедә катнашырга теләүче Министрлыкның дәүләт хезмәткәрләре түбәндәге документларны бирә:

шәхси гариза.

Бәйге 20___елның «___»__________ _____сәгатьтә үткәрелә.

Бәйге комиссиясе 420111, Казан ш.,Островский ур., 11/6, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Кадрлар бүлеге, бүлмә №106 адресы буенча урнаша, телефон: (843)231-79-17, (843)231-79-15, факс: (843)231-79-15, e-mail: _______________
Тулырак мәгълүмат - minzdrav.tatarstan.ru сайтында

* Урнашыла торган вазыйфага куелган таләпләр белән бәйле

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында дәүләт
граждан хезмәтенең вакант
вазыйфасына урнашуга бәйге
үткәрү турындагы положениегә
кушымта № 4

Форма

Дәүләт граждан хезмәтенең
вакант вазыйфасына урнашуга бәйге үткәрү турында
мәгълүмат

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (420111, Казан ш., Островский ур., 11/6, телефоннар: (843)231-79-17, (843)231-79-15, факс: (843)231-79-15, e-mail: _______________) исеменнән 22.02. 2013 булган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары №128 тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы турында Положение нигезендә эш итүче министр ________________, ______________________________________________
(бүлекнең, Идарәнең граждан вазыйфасы исемлеге)
дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга бәйге (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар резервына кертүгә бәйге) үткәрүне күздә тота.

1. Бу вазыйфага урнашуга претендентка түбәндәге таләпләр куела:
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

2. Бәйгедә катнашу өчен документлар кабул итү 20__елның «___» __________ ___сәгатьтә башлана, 20__елның «___»__________ ___сәгатьтә тәмамлана.

3. Документлар кабул итү урыны адресы 420111, Казан ш., Островский ур., 11/6, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Кадрлар бүлеге, бүлмә №106, телефон: (843)231-79-17, (843)231-79-15, факс: (843)231-79-15. Документлар кабул итү өчен җаваплы ______________________________________________________

4. Бәйгедә катнашу өчен гражданин түбәндәге документларны тапшыра:

а) шәхси гаризаны;

б) үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкетаны;

в) паспорт күчермәсен яки аны алыштыручы документны (тиешле документ бәйгегә килгәч шәхсән тапшырыла);

г) тиешле һөнәри белемне, хезмәт стажын һәм квалификацияне раслаучы документларны:

хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт итү (хезмәт) эшчәнлеген беренче тапкыр башкарган очраклардан кала) яки гражданинның хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген

раслаучы бүтән документларны;

һөнәри белеме турындагы, шулай ук гражданин теләге буенча - нотариус яки эш урыны буенча кадрлар хезмәтләре (хезмәте) тарафыннан расланган өстәмә һөнәри белеме турындагы, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турындагы документларның күчермәләрен;

д) гражданинда граждан хезмәтенә урнашуга яки аны үтүгә киртә булучы авыруларның булмавы турында медицина йомгаклавын (001 -ГС/у формасы);

е) кабул ителгән формадагы анкетаны - хезмәт вазыйфаларын үтәү дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны куллану белән бәйле булган граждан вазыйфасына урнашуга бәйгедә катнашучы кандидатлар өчен;

ж) почмакчыксыз каралы-аклы сурәттә ялтыравыксыз кәгазьдә эшләнгән ике фотография (4х6);

з) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закончылыгы тарафыннан күздә тотылган бүтән документлар.

5. Бәйгедә катнашу өчен граждан хезмәткәре түбәндәге документларны тапшыра:

а) шәхси гариза.

6. Бәйге 20___ елның «____»____________ ____ сәгатьтә 420111, Казан ш., Островский ур., 11/6, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, бүлмә №106 адресы буенча үткәрелә.

Бәйгегә нәтиҗәләр ясау бәйге бетеп _____ сәгать үткәннән соң (бәйге беткәннән соң икенче көнне _____ сәгатьтә шул ук адрес буенча) булачак.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында дәүләт граждан
хезмәтенең вакант вазыйфасына
урнашуга бәйге үткәрү
турындагы положениегә
кушымта № 5

Форма БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ

Хөрмәтле ___________________________________ !

Сезгә

а) сезнең граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы квалификациясенең таләпләренә туры килмәвегез;

б) граждан хезмәтенә урнашу һәм аны үтү өчен дәүләт граждан хезмәте турындагы Россия Федерациясе закончылыгы тарафыннан билгеләнгән чикләнүләр;

в) сезнең нигезле сәбәп булмаганда документларны вакытында тапшырмавыгыз (аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыруыгыз);

г) тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокук актларына туры китереп гражданинның граждан хезмәтенә урнашуына киртә булучы шартлар ачыклану белән бәйле

_____________________________________________________________________ дәүләт граждан
(граждан вазыйфасы, бүлек исеме)

хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашу бәйгесендә катнашуга (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар резервына кертүгә бәйгедә катнашуга) рөхсәт ителмәвегез турында хәбәр итәм.

Документлар Сезгә 420111, Казан ш., Островский ур., 11/6, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Кадрлар бүлеге, бүлмә №106 адресы буенча язма гариза буенча кайтарылырга мөмкин, телефон: (843)231-79-17, (843)231-79-15, факс: (843)231-79-15.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында дәүләт граждан
хезмәтенең вакант вазыйфасына
урнашуга бәйге үткәрү
турындагы положениегә
кушымта № 6

Форма

БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ

Хөрмәтле ___________________________________!

Сезнең ________________________________________________ дәүләт граждан
(граждан вазыйфасы, бүлек исеме)

хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашу бәйгесендә катнашуга (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар резервына кертүгә бәйгедә катнашуга) рөхсәт ителүегез турында хәбәр итәм.

Бәйге 20____елның «___»___________ _____сәгатьтә 420111, Казан ш., Островский ур., 11/6, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Кадрлар бүлеге, бүлмә №106 адресы буенча үткәрелә, телефон: (843)231-79-17, (843)231-79-15, факс: (843)231-79-15.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында дәүләт граждан
хезмәтенең вакант вазыйфасына
урнашуга бәйге үткәрү турындагы
положениегә кушымта № 7

Форма

_______________________________________________
(вакант вазыйфа исеме)
вакант вазыйфасына урнашуга кандидат
_______________________________________________ның
(кандидатның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
һөнәри и шәхси сыйфатларын бәяләү
анкетасы

| № т/б | Кандидатның сыйфатын бәяләү күрсәткечләре | Кандидат квалификациясенең куелган таләпләргә туры килү дәрәҗәсе | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Һөнәри белем дәрәҗәсе | туры килә | билгеле хәзерләнү булганда туры киләчәк | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| 2. | Һөнәри яңадан укытуны һәм квалификация күтәрүне үтү | туры килә | | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| 3. | Белгечлек буенча стаж һәм эш тәҗрибәсе | туры килә | | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Кадрлар бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| 4. | РФ Конституциясе һәм ТР Конституциясен, федераль законнар и ТР законнарын, эшчәнлек юнәлеше буенча җитәкчелек итүче документларны белү дәрәҗәсе | туры килә | билгеле хәзерләнү булганда туры киләчәк | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар бүлеге вәкиле | | | |
| | Юридик бүлек вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| 5. | Һөнәри, эшлекле һәм шәхси сыйфатларның дәрәҗәсе | туры килә | билгеле хәзерләнү булганда туры киләчәк | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар бүлеге вәкиле | | | |
| | Юридик бүлек вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| 6. | Хәтере (төре, истә калдыру тизлеге, истә калдыру дәвамлылыгы) | туры килә | | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Бәйсез эксперт | | | |
| 7. | Игътибарының күләме һәм тотрыклылыгы | туры килә | | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| 8. | Шәхси сыйфатлары (үз-үзен бәяләүгә сәләтле булуы, психологик тотрыклылыгы) | туры килә | | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| 9. | Сөйләм культурасы, сөйләшү манерасы, тышкы кыяфәте | туры килә | | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| 10. | Үз фикерләрен язмача һәм телдән җиткерергә сәләтле булуы | туры килә | | туры килми |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар бүлеге вәкиле | | | |
| | Юридик бүлек вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |

| 11. | Кандидатны гомуми бәяләү | вакант вазыйфага туры килә | билгеле хәзерләнү булганда вакант вазыйфага туры киләчәк | вакант вазыйфага туры килми |
|---|---|---|---|---|
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар бүлеге вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Нәтиҗә | Вакант вазыйфага урнашуны тәкъдим итәргә | Кандидатка Министрлык-ның кадрлар резервында вазыйфа тәкъдим итәргә | Вакант вазыйфага граждан хезмәтенә кабул итүне кире кагарга |
| | Җитәкче урынбасары | | | |
| | Структур бүлекчә вәкиле | | | |
| | Кадрлар сәясәте бүлеге вәкиле | | | |
| | Юридик бүлек вәкиле | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |
| | Бәйсез эксперт | | | |

Йомгаклау:

Бәйге комиссиясе рәисе ______________________________
(имза, имзаны аңлату)

Бәйге комиссиясе сәркатибе __________________________
(имза, имзаны аңлату)

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында дәүләт граждан
хезмәтенең вакант вазыйфасына
урнашуга бәйге үткәрү
турындагы положениегә
кушымта № 8

Форма

# БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ

Хөрмәтле ______________________________________________________!

Сезнең _________________________________________________________ дәүләт граждан
(граждан вазыйфасы, бүлек, Идарә исеме)
хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашу бәйгесендә (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар резервына кертүгә бәйгедә) җиңүче булып сайлануыгыз турында хәбәр итәм.

Сезнең ________________________________________________________ дәүләт граждан
(вазыйфа, бүлек, Идарә исеме)
хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуыгыз турындагы мәсьәләне чишү һәм дәүләт граждан хезмәтен үтү һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына урнашу турында хезмәт контрактын төзү өчен 20___елның «___»______________420111, Казан ш., Островский ур., 11/6, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, кадрлар бүлеге, бүлмә №106 адресы буенча ____ сәгатьтә килүегезне сорыйм, телефоннар: (843) 231-79-17, (843) 231-79-15.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында дәүләт граждан
хезмәтенең вакант вазыйфасына
урнашуга бәйге үткәрү
турындагы положениегә
кушымта № 9

Форма

Бәйге нәтиҗәләре турында мәгълүмат

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (420111, Казан ш., Островский ур., 11/6 телефоннар: (843) 231-79-17, (843) 231-79-15, факс: (843)231-79-15, e-mail:__________) исеменнән 22.02.2013 булган №128 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы турында Положение нигезендә эш итүче министр ____________________ ____________________________________________________

(граждан вазыйфасы, бүлек, Идарә исеме)

дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга бәйге (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар резервына кертүгә бәйге) үткәрде.

Белемнәренә, граждан яки башка дәүләт хезмәтен үтү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турындагы тапшырылган документларына нигезләнеп, шулай ук сайлап алынган бәйге процедуралары нигезендә кандидатларны бәяләү нәтиҗәсендә бәйге җиңүчесе итеп ____________________________________________________танылды.

(кандидатның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

Бәйге нәтиҗәләре буенча ________________________________________________ны

(кандидатның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләү турында 20____елның «____»_______________ булган № ____ Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы басылды.

Калган претендентларга ______________________________________________________

(кандидатларның фамилияләре, исемнәре, әтиләренең исемнәре)

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләнү (кадрлар резервына кертелү) рөхсәт ителмәде.

Документлар аларга 420111, Казан ш., Островский ур., 11/6, Кадрлар бүлеге, бүлмә №106 адресы буенча язма гариза буенча кайтарылырга мөмкин, телефон: (843) 231-79-17, (843) 231-79-15, факс: (843) 231-79-15.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры

__________булган №___
ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгына
кушымта № 2

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга кандидатларга таләпләр

1. Гомуми таләпләр

1.1. Бәйгедә катнашырга дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашу өчен кирәк булган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнчылыгы тарафыннан куелган таләпләргә туры килүче 18 яшьтән дә яшьрәк булмаган Россия Федерациясенең дәүләт телендә сөйләшүче Россия Федерациясе гражданнарының хокуклары бар.

1.2. Гражданинга түбәндәге очракта бәйгедә катнашырга рөхсәт ителми:

а) аны законлы көчкә кергән суд карары белән эшкә яраксыз яки чикләнгән эшкә яраклы дип таныган очракта;

б) аның дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы буенча хезмәт вазыйфаларын үтәү мөмкинлегенә юл куймаучы законлы көчкә кергән суд хөкеме буенча җәзага тартылуы, шулай ук федераль закон белән урнаштырылган тәртиптә кире алынмаган яки капланмаган хөкемгә тартылуы булган очракта;

в) аның вазыйфа бурычларын үтәвенә киртә булучы медицина оешмасы йомгаклавы тарафыннан расланган авыруы булуы;

г) дәүләт серен яки бүтән закон тарафыннан саклана торган серне тәшкил итүче мәгълүматларга рөхсәт алуны рәсмиләштерү процедурасын үтүдән баш тарту;

д) гражданинның дәүләт хезмәткәре белән якын туганлыгы (ата-аналары, ире белән хатыны, абыйлары, апалары, уллары, кызлары, шулай ук ир белән хатынның абыйлары, апалары, ата-аналары һәм балалары), әгәр аның моңа кадәрге дәүләт хезмәте бер-берсенә турыдан-туры буйсыну белән бәйле яки алар бер-берсенең тикшерүе астында булса;

е) Россия Федерациясе гражданлыгының бетүе, дәүләт хезмәтенә рөхсәт үзара нигездә илләр арасындагы килешүләр белән җайга салынган очраклардан тыш чит ил гражданлыгының булуы;

ж) милек хокуклары буенча аныкы булган налог алынучы объектлар булып торучы кергән табышлары һәм милеге турындагы мәгълүматларны тапшырудан баш тарту;

з) дәүләт хезмәтенә эшкә кергәндә ялган документлар яки билгеле ялган мәгълүматлар тапшыру.

## 2. Квалификация таләпләре

2.1. дәүләт хезмәте вазыйфаларының югары группасының «белгеч» категориясе дәүләт хезмәте вазыйфаларына урнашу өчен югары һөнәри белеме, баш яки әйдәүче группаның дәүләт хезмәте вазыйфаларында өч елдан да ким булмаган дәүләт хезмәте стажы яки белгечлек буенча биш елдан да ким булмаган хезмәт стажы булуы;

дәүләт хезмәте вазыйфаларының төп группасының бөтен категорияләренең дәүләт хезмәте вазыйфаларына урнашу өчен - югары һөнәри белеме, әйдәүче яки өлкән группаның дәүләт хезмәте вазыйфаларында ике елдан да ким булмаган дәүләт хезмәте стажы яки белгечлек буенча өч елдан да ким булмаган хезмәт стажы булуы;

дәүләт хезмәте вазыйфаларының югары группасының бөтен категорияләренең дәүләт хезмәте вазыйфаларына урнашу өчен - югары һөнәри белеме, өлкән яки кече группаның дәүләт хезмәте вазыйфаларында бер елдан да ким булмаган дәүләт хезмәте стажы яки белгечлек буенча ике елдан да ким булмаган хезмәт стажы булуы;

дәүләт хезмәте вазыйфаларының зур группасының «белгечләр» һәм «тәэмин итүче белгечләр» категорияләренең дәүләт хезмәте вазыйфаларына урнашу өчен - эшчәнлек юнәлешенә туры килүче урта һөнәри белеме булуы;

дәүләт хезмәте вазыйфаларының кече группасының «тәэмин итүче белгечләр» категориясенең дәүләт хезмәте вазыйфаларына урнашу өчен дәүләт хезмәте стажына яки эш белгечлеге буенча стажга (тәҗрибәгә) квалификация таләпләре билгеләнми.

2.2. Вазыйфа бурычларын үтәү өчен кирәк булган һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә квалификация таләпләре дәүләт хезмәткәренең вазыйфалар регламенты белән билгеләнгән.

__________булган №___
ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгына
кушымта № 3

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга гражданнар тарафыннан тапшырылучы
документлар һәм материаллар исемлеге

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры исеменә шәхси гариза.

2. Кандидатның шәхесен раслаучы документ күчермәсе (паспорт, хәрби билет, шәхес таныклыгы).

3. Ике 4х6 фотография һәм үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета.

4. Һөнәри белеме турындагы, шулай ук гражданин теләге буенча - нотариус яки эш урыны буенча кадрлар хезмәтләре (хезмәте) тарафыннан расланган өстәмә һөнәри белеме турындагы, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турындагы документларның күчермәләре.

5. Хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт итү (хезмәт) эшчәнлеген беренче тапкыр башкарган очраклардан кала) яки гражданинның хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслаучы бүтән документлар.

6. Гражданинда граждан хезмәтенә урнашуга яки аны үтүгә киртә булучы авыруларның булмавы турында медицина йомгаклавы (001 -ГС/у формасы).

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан тапшырылучы документлар һәм материаллар исемлеге

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры исеменә шәхси гариза.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга кандидатлар тарафыннан тапшырылучы документлар һәм материаллар исемлегенә кушымта

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрына
_____________________________
(инициаллары, фамилиясе)
____________________________дан
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
Яшим ________________________
Тел.__________________________
(эшнеке, өйнеке)

Гариза.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәтенең ________________________________________________ вакант вазыйфасына
(вазыйфа исеме, бүлек, Идарә исеме)
урнашуга (Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашу өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар резервына кертү өчен) бәйгедә катнашырга рөхсәт итүегезне сорыйм.

2004 елның 27 июленнән булган № 79-ФЗ «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында»гы Федераль закон, 2003 елның 16 гыйнварыннан булган № 3-ЗРТ «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында»гы Татарстан Республикасы Законы, 2005 елның 1 февраленнән булган № 112 «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашу бәйгесе турында»гы Россия Федерациясе Президенты Указы белән, Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга бәйге үткәрү турындагы положение, шул санда вакант вазыйфага куелучы квалификация таләпләре белән таныштым.

Гаризага терким______________________________________________
(теркәлүче документларны санап чыгарга).

(дата, имза, имзаны аңлату)

__________булган №___
ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгына
кушымта № 4

Бәйгедә катнашучыларны бәяләү критерийлары

1. Дәүләт хезмәте культурасына туры килү

1.1. Һөнәри мотивация:

Дәүләт хезмәтендә һөнәри үз-үзеңне реальләштерүгә омтылу, дәүләт идарәсе өлкәсендә хезмәт үсешенә ориентлашу.

1.2. Граждан позициясе:

Эшчәнлегендә җәмгыятькә һәм дәүләткә хезмәт итү принципларында тору, законнарны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен үтәү.

1.3. Һөнәри позициясенең активлыгы:

куелган мәсьәләләрне чишү вакытында инициатива күрсәтергә омтылу; мөмкин булган нәтиҗәләрнең иң яхшысына ирешү өчен җитди көч куярга әзер булу; физик һәм эмоциональ йөкләнеш шартларында нәтиҗәле эш итә алу (стресска тотрыклылык).

1.4. Үз-үзен үстерергә әзер булуы:

Үзенең белемнәрен, осталыкларын һәм күнекмәләрен камилләштерергә, белем дәрәҗәсен киңәйтергә, эргәдәш һөнәри өлкәләрдә белемнәр һәм тәҗрибә алырга даими омтылуы.

2. Дәүләт хезмәткәренең һөнәри компетентлылыгы.

2.1. Белем дәрәҗәсе:

Төп һәм өстәмә һөнәри белеменең дәрәҗәсе, профиле һәм сыйфаты.

2.2. Һөнәри тәҗрибәсе:

Тиешле һөнәри өлкәдә эшчәнлегенең дәвамлылыгы һәм үзенчәлекләре; һөнәри эшчәнлегендә билгеле нәтиҗәләргә ирешүе; карьерасының үзенчәлекләре.

2.3. Махсус һөнәри белемнәре, осталыклары һәм күнекмәләре:

Функциональ бурычларны нәтиҗәле башкарырга мөмкинлек бирә торган тиешле өлкәдәге һөнәри белемнәрнең дәрәҗәсе; һөнәри эшчәнлекне тәртипкә салучы Россия Федерациясе закончылыгын белү; заман һөнәри технологияләре белән эш итә белү.

2.4. Гомуми инструменталь күнекмәләр:

Һөнәри эшчәнлекнең гомуми нәтиҗәлелеген күтәрүче күнекмәләргә ия булу дәрәҗәсе, (компьютер белән эш итә алу, гомуми грамоталылык, чит телләр белү һ.б.).

3. Дәүләт хезмәткәренең шәхси-эшлекле сыйфатлары.

3.1. Аналитик сәләтләре:

Мәгълүматны анализлауны һәм тәртипкә салуны таләп итүче катлаулы мәсьәләләрне чишәргә мөмкинлек бирә торган фикерләвенең системалылыгы һәм сизгерлеге дәрәҗәсе; яңа, стандарт булмаган чишелешләр табу сәләте.

3.2. Нәтиҗәле аралашу күнекмәләре:

Эшлекле аралашу этикасын саклау; үз карашыңны аргументлы яклау һәм оппонентларны ышандыру сәләте; эшлекле сөйләшүләр алып бару күнекмәләренә ия булу.

3.3. Җаваплылык:

Карарларга килүдә төплелек һәм мөстәкыйльлек; нәтиҗәгә ирешүдә үзенә алган йөкләмәләр буенча эш итәргә әзерлек.

3.4. Оештыру сәләтләре:

Үз эшчәнлеген һәм кул астындагы кешеләрнең эшчәнлекләрен нәтиҗәле планлаштыру, функцияләрне, вәкаләтләрне һәм җаваплылыкларны бүлеп бирү исәбенә нәтиҗәгә ирешү осталыгы.